«РАСЛЫЙМ»
Татарстан Республикасы
Язучылар берлеге рәисе
_____________ Р.Р.Зәйдуллин

Габдулла Тукайның 140 еллык юбилее уңаеннан
**«Тукай йолдызлыгы»** дип аталган
Татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсы нигезләмәсе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә татар телендәге әсәрләр конкурсы (алга таба – Конкурс) үткәрү шартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Конкурсны үткәрү максатлары – татар телен саклау һәм үстерү, татар әдәбиятын яңа әсәрләр белән баету, татар язучыларын иҗат итәргә кызыксындыру, татар телендә әдәби әсәрләр иҗат итүче яңа авторларны барлау, Габдулла Тукай һәм аның чордашлары исемен мәңгеләштерү, мәктәп укытучылары, балалар бакчалары тәрбиячеләре арасында шагыйрь иҗатына, шәхесенә игътибарны арттыру.

1.3. Бәйгене Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Татарстан Республикасы Язучылар берлеге оештыра.

1.4. Конкурс түбәндәге сигез номинациядә үткәрелә:

1. «Шигырьләр шәлкеме» – Тукай, аның чоры һәм XX гасыр татар дөньясына багышланган шигырьләр *(10 шигырьдән дә ким түгел).*
2. «Поэма» – Тукай һәм аның чоры турында поэма.
3. «Хикәя» – Тукай һәм аның чоры турында хикәя *(10-25 бит тирәсе).*
4. «Бәян» – Тукай һәм аның чоры турында повесть *(70 биттән дә ким түгел)*
5. «Пьеса» – Тукай һәм аның чоры турында пьеса.
6. «Эссе» – Тукай һәм аның чоры турында эссе *(фәнни яки сәнгати шәкелдә, 15-20 бит тирәсе).*
7. «Тукай дәресе» – Тукай һәм аның чоры турында татар әдәбиятыннан ачык дәрес планы.
8. «Тукай тәрбиясе» – Тукай һәм аның чоры турында татар балалар бакчалары өчен тәрбия дәресе планы.

## 2. Конкурсны уздыру шартлары, әдәби әсәрләргә таләпләр

2.1. Конкурста катнашу өчен татар телендә язылган, моңа кадәр гаммәви мәгълүмат чараларында, төрле җыентыкларда басылмаган әсәрләр һәм дәрес планнары кабул ителә. Бер автордан килгән әсәрләр саны чикләнми.

2.2. Конкурста катнашучыларның исемнәре жюри әгъзаларына билгеле булмый.

2.3. Текстларны Бәйгенең «MS Word» форматында («Times New Roman» шрифты, 14 pt, 1,5 интервал) gabdullatukay140@mail.ru электрон адресына җибәрергә кирәк. (ZIP программасында архивлап җибәрү мөмкин). Бәйгегә тәкъдим ителә торган әсәрнең титул битендә фаразланган номинацияне күрсәтергә кирәк.

2.4. Әсәр аерым файлда беркетелергә һәм латин графикасында «Avtor_Nazvanie» дип исемләп җибәрелә.

2.5. Әсәр тексты белән бергә автор турында анкета тутырыла: фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган көне, эш/уку урыны; кыска иҗади биографиясе; индекс күрсәтелгән почта адресы: шәһәр һәм мобиль телефон номерлары, электрон адрес, пьеса исеме һәм аны язу датасы (тәкъдим ителә торган номинацияне күрсәтергә). Бу белешмәләрдән башка текстлар каралмаячак;

2.6. Бер номинациядә бары тик бер әсәр белән генә катнашу мәҗбүри.

2.7. Конкурска җибәрелгән әдәби әсәрләр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

2.8. Комиссия әгъзасы, «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы – «Казан утлары» журналы редакциясе җитәкчесе, баш мөхәррире Р.Г. Галиуллин әсәрләрне кабул итү, аларның Конкурс шартларына һәм аны үткәрү вакытына туры килү-килмәвен тикшерү эшен оештыра һәм әсәрләрне авторын күрсәтмичә кичекмәстән Жюри әгъзаларына тапшыра.

2.9. Конкурста катнашу өчен әсәрләр 2026 елның 21 февраленә кадәр кабул ителә.

2.10. Билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән, шул исәптән күрсәтелгән вакыттан соң тапшырылган әсәрләр Конкурста катнашмый.

2.11. Комиссия әгъзалары һәм Жюри әгъзалары Конкурста катнаша алмый.

## 3. Конкурс нәтиҗәләрен чыгару, җиңүчеләрне билгеләү һәм бүләкләү

3.1. Оештыру төркеме һәр әсәргә номер бирә һәм, авторын күрсәтмичә, Жюри әгъзаларына тапшыра.

3.2. Жюри әгъзалары, түбәндәге таләпләргә нигезләнеп, һәр әсәргә кыскача бәяләмә әзерли:

– әсәрләрнең әдәби-эстетик кыйммәте һәм яңалыгы;
– тел-сөйләм төзеклеге һәм матурлыгы;
– дәрес планнарының әхлакый кыйммәте, яшь буынга әһәмияте;

– текстның заманчалыгы.

3.3. 2026 елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, жюри җиңүчеләр итеп расланырга тәкъдим ителәчәк әсәрләр авторларын Комиссиягә тәкъдим итә.

3.4. Жюри карарлары коллегиаль рәвештә кабул ителә.

3.5. Әсәрләрне караганда Жюри әгъзаларына автор билгеле булмый. Авторлар турындагы белешмәләр Жюри Конкурста җиңүчеләр итеп тәкъдим ителәчәк әсәрләрне билгеләгәннән соң гына ачыклана.

3.6. Жюри үз карарларын беркетмәләр белән рәсмиләштерә һәм аларны Комиссиягә Конкурс нәтиҗәләрен раслау өчен тапшыра.

3.7. Конкурс нәтиҗәләрен раслаганчы, Комиссия әгъзасы, «Татарстан китап нәшрияты» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры И.К. Сәгъдәтшин Жюри тарафыннан җиңүчеләр итеп расланырга тәкъдим ителгән әдәби әсәрләр авторларының әдәби әсәрләргә үз хокукларын тиешле шартнамә нигезендә «Татарстан китап нәшрияты» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә тапшыру эшен оештыра. Әлеге шартнамә төзелмәгән очракта, әдәби әсәр Конкурстан төшереп калдырыла һәм бу номинациядәге урынга җиңүче билгеләнми.

3.8. Жюри бернинди дә призлы урыннар бирмәскә яки аерым номинацияләр һәм катнашучылар категорияләре буенча берничә призлы урыннар бирергә хокуклы.

3.9. Конкурс нәтиҗәләре Комиссия тарафыннан расланa. Һәр номинациядә 3 (өч) җиңүче һәм 3 (өч) җиңүче кызыксындыру бүләге билгеләнә һәм алар түбәндәге күләмдә акчалата премия белән бүләкләнә:

**«Шигырьләр шәлкеме» номинациясендә:**
I урын – 100 000 сум
II урын – 75 000 сум
III урын – 50 000 сум.
30 мең сумлык өч кызыксындыру премиясе

**«Поэма» номинациясендә:**
I урын – 200 000 сум
II урын – 150 000 сум
III урын – 100 000 сум.
50 мең сумлык өч кызыксындыру премиясе

**«Хикәя» номинациясендә:**
I урын – 100 000 сум
II урын – 75 000 сум
III урын – 50 000 сум.
30 мең сумлык өч кызыксындыру премиясе

**«Бәян» номинациясендә:**
I урын – 200 000 сум
II урын – 150 000 сум
III урын – 100 000 сум.
50 мең сумлык өч кызыксындыру премиясе

**«Пьеса» номинациясендә:**
I урын – 200 000 сум
II урын – 150 000 сум
III урын – 100 000 сум.
50 мең сумлык өч кызыксындыру премиясе

**«Эссе» номинациясендә:**
I урын – 100 000 сум
II урын – 75 000 сум
III урын – 50 000 сум.
20 мең сумлык өч кызыксындыру премиясе

**«Тукай дәресе» номинациясендә:**
I урын – 100 000 сум
II урын – 75 000 сум
III урын – 50 000 сум.
20 мең сумлык өч кызыксындыру премиясе

**«Тукай тәрбиясе» номинациясендә:**
I урын – 100 000 сум
II урын – 75 000 сум
III урын – 50 000 сум.
**20 мең сумлык өч кызыксындыру премиясе**

3.10. Конкурста җиңүчеләрне Телләр Комиссия рәисе һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе бүләкли.

3.11.Җиңүчеләрнең әсәрләре «Казан утлары» әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журналында һәм башка басмаларда дөнья күрәчәк.